ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авылында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 2 12.11. 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Уразбахты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү ) Пионер урамы, Уразбахты авылы;
- Уразбахты авылы урам юлларын кардан чистарту;
- җәй көне Уразбахты авылында юлларны кырдырып тигезләү;
- Уразбахты авылында чишмәләрне төзекләндерү (сатып алу, материалларны ташу, ремонт, төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);

3. Әлеге карарны Уразбахты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Шәйхетдинов